Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Колай авыл җирлеге Советы

Колай авыл җирлеге башлыгы
КАРАРЫ

25 март, 2026 ел № 10

Җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү буенча гавами тыңлаулар үткәрү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Колай авыл җирлегендә 2017 елның 21 августындагы 20 номерлы (2017 елның 14 маендагы 38 номерлы, 2018 елның 25 маендагы 12 номерлы, 2019 елның 20 сентябрендәге 50 номерлы, 2022 елның 15 декабрендәге 63 номерлы, 2023 елның 31 мартындагы 70 номерлы үзгәрешләре белән) белән расланган гавами тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмә нигезендә карар бирәм:

1.Түбәндәге проект буенча гавами тыңлаулар үткәрүне билгеләргә:

- Татарстан Республикасы, Питрәч муниципаль районы, Колай авыл җирлеге, Колай авылы адресы буенча урнашкан 16:33:050102:631 кадастр номерлы, 2000 кв.м мәйданлы җир кишәрлегеннән - Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы «Колай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренең индивидуаль торак төзелеше зонасында (Ж1) «кунакханә хезмәте күрсәтү», «автомобиль юу урыннары» файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы боерыгы проекты.

2. Гавами тыңлауларны үткәрүне оештыручыны - Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Колай авыл җирлеге башкарма комитеты билгеләргә.

3. Гавами тыңлауларны оештыручыга - Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Колай авыл җирлеге башкарма комитетына җирле үзидарә турындагы, шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы кануннар нигезендә гавами тыңлауларны оештыруны һәм уздыруны тәэмин итәргә.

4. Гавами тыңлаулар үткәрү 2026 елның 10 апреленнән дә соңга калмыйча тәгәлләнергә тиеш дип билгеләргә.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы
Колай авыл җирлеге башлыгы Н.В.Поповская